| БАВЛИНСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре №131

Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Баулы шәһәре прокуратурасың 2024 елның 15 гыйнварындагы 02-08-02/24 номерлы протесты нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 18 сентябрендәге 573 номерлы «Дәүләт серенә даими нигездә кертелгән гражданнарга һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә социаль гарантияләр бирү турында» («даими нигездә дәүләт серенә кертелгән гражданнарның һәм дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакына (тариф ставкасына) айлык процент өстәмәләрен түләү кагыйдәләре» белән бергә) карары белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләре, рәис урынбасарлары, аудиторлары, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, Баулы

шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2018 елның 20 апрелендәге 72 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» карарына (2018 елның 28 сентябрендәге 89 номерлы, 2020 елның 28 августындаг 139 номерлы, 2021 елның 14 декабрендәге 44 номерлы, 2022 елның 26 октябрендәге 69 номерлы, 2022 елның 16 декабрендәге 80 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 пунктның 3 абзацында «12 688» саннарын «13 323» саннары белән алмаштырырга;

5 номерлы кушымтада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алмаштырырга;

11 номерлы кушымтаның 1 пунктында:

6) пунктчада «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алмаштырырга;

7) пунктча белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«7) нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле фәнни дәрәҗә өчен - вазифа хезмәт хакына айлык өстәмә вазифа хезмәт хакының 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.»;

күрсәтелгән карарга 14 номерлы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушыла).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Бавлы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы Рәисе И.И. Гозәеров

Баулы шәһәр Советының
2018 елның 20 апрелендәге
72 номерлы карарына
14 номерлы кушымта

(шәһәр Советы
карар редакциясендә

«____»_____2024 ел ___

Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләгәне өчен айлык процент өстәмәсе күләме һәм муниципаль хезмәткәрнең вазифа хезмәт хакы күләме

| Айлык процент өстәмәсе | Процент өстәмәсе |
|---|---|
| «Аеруча мөһим» серлелек дәрәҗәсенә ия булган мәгълүматлар белән эшләгәне өчен | 50-75 |
| «Бөтенләй сер» серлелек дәрәҗәсе булган мәгълүмат белән эшләгәне өчен | 30-50 |
| Тикшерү чараларын үткәргәндә рөхсәт алуны рәсмиләштергәндә «яшерен» серлелек дәрәҗәсенә ия булган мәгълүматлар белән эшләгән өчен, | 10-15 |
| тикшерү чаралары үткәрелмичә | 5-10 |
| Структура бүлекчәләрендә дәүләт серен саклау буенча эш стажы өчен: | |
| 1 елдан 5 елга кадәр | 10 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 15 |
| 10 елдан һәм аннан да күбрәк | 20 |

* Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматлар белән эшләү өчен процент өстәмәсе һәм муниципаль хезмәткәрнең вазифа хезмәт хакы күләме муниципаль хезмәткәрнең бурычларыннан чыгып, яллаучы (эш бирүче) вәкиле боерыгы нигезендә исәпләнә